КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 декабрь

г.Казань

№ 1397

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары белән расланган Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау хакында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 гыйнвар, 3 нче; 2015 ел, 12 февраль, 85 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 706 нчы; 2018 ел, 9 ноябрь, 984 нче, 2021 ел, 19 ноябрь, 1106 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә (алга таба - Тәртип), аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 2023 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бүтән бюджетара трансфертлар бирү максатларында түбәндәгеләрне билгеләргә:

Тәртипнең 2 пункты нигезләмәләре исәпкә алынмый;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, күрсәтелгән максатларга 2023 елда «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган Татарстан Республикасы бюджеты күләменнән чыгып, Тәртипнең 6 пункты нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын гамәлгә ашыруга гражданнарның үзара салым акчаларының норматив күләмен исәпләп чыгара һәм 2023 елның 15 гыйнварына кадәр аны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарына (шәһәр округларына) җибәрә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин